| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет Лешев-Тамакского сельского поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Ләшәү Тамак авыл җирлеге<br>башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның, 12 апреле №7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе турында» 2021 елның 15 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе турында» 2021 елның 15 мартындагы 2 номерлы карарына (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Аналитик белешмәдә кергән, яңадан адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул иткәндә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүмат булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.З.Хабибуллин

Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Башкарма комитетының 12
апрель 2021елның 7 нче
номерлы карарына

1 нче кушымта

(2021 елның 15 мартындагы 2
номерлы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе.

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү өчен эшләнде һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ел саен башкарыла.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә кергән, яңадан адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси кабул

итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре ел саен аналитик белешмәнең Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Авыл җирлекләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштырылуын тәэмин итә.